ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 81-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 81-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 316-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты
тарафыннан кертелә

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 статьяның 1 өлешендә «3.2 – 3.6» саннарыннан соң «, 3.16, 3.17, 3.19» саннарын өстәргә;

2) 3.6 статьяның 1 өлешендә «3.17статьясында» сүзен «3.17, 3.19 статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3.16 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнарга – ике мең биш йөз сум, юридик затларга биш мең сум күләмендә административ штраф салына.»;

4) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.19 өстәргә:

«3.19 статья. **Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенә таләпләрне бозу**

Йөк транспорты чарасын арбадагы (контейнердагы) чәчелүчән йөкләрне, чүп-

чарны, җиңел тараны, киселгән агачларны, яфракларны брезент яисә башка материал белән капламыйча файдалануда чагылган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенең җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләрен бозган өчен –

гражданнарга – биш мең сум күләмендә; юридик затларга илле мең сум күләмендә административ штраф салына.»;

5) 7.4 статьяда «3.17,» саннарыннан соң «3.19,» саннарын өстәргә;

6) 8.1 статьяның 14 өлешендә «3.17,» саннарыннан соң «3.19,» саннарын өстәргә;

7) 8.3 статьяда «3.17,» саннарыннан соң «3.19,» саннарын өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), «3.14 – 3.17,» саннарыннан соң «3.19,» саннарын өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты административ хокук бозулар турындагы Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү максатыннан эшләнде.

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү түбәндәгеләргә бәйле рәвештә барлыкка килде:

1. Хәзерге вакытта Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының гамәлдәге редакциясендә түләүле муниципаль парковкалардан файдалану тәртибен бозган өчен 3.16 статьяда физик затлар өчен дә, юридик затлар өчен дә 2500 сум күләмендә бер төрле административ штраф каралган.

3.16 статьяга үзгәреш кертеп, физик һәм юридик затлар арасында җаваплылыкны бүлү тәкъдим ителә. Физик затлар өчен штраф күләме элеккеге күләмдә – 2500 сум, юридик затлар өчен 5000 сум күләмендә тәкъдим ителә.

Хәзерге вакытта транспорт чарасын түләүле муниципаль парковкага куйган өчен түләмәгән очракта штраф күләме 2500 сум тәшкил итә, бу икътисадый яктан отышлы түгел. Статистика мәгълүматлары нигезендә, Казан шәһәрендә 3.16 статья буенча җаваплылыкка тартылган юридик затларның 80 проценты кече һәм урта эшкуарлык субъектлары категориясенә карый һәм, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $4.1^2$ статьясы нигезләмәләренә таянып, 1250 сум күләмендә штраф түли. Алар шәһәр үзәгендә иң кирәкле урыннарны көне буе биләп, башкаларны машина кую мөмкинлегеннән мәхрүм итә.

Моннан тыш, юридик затлар, кагыйдә буларак, хуҗалык эшләре белән шөгыльләнә, транспорт чарасы алар өчен керем алу чыганагы булып тора һәм алар машина йөртүчеләрнең эшен тиешле рәвештә оештыру мөмкинлегенә дә ия. Шуңа бәйле рәвештә аларның җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән парковка кагыйдәләрен бозуы зуррак җаваплылык билгеләүне таләп итә.

Тәкъдим ителә торган закон проекты шундый хокук бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән.

2. Бүгенге көндә чәчелүчән йөкләрне, чүп-чарны, җиңел тараны, киселгән агачларны, яфракларны брезент яисә башка материал белән капламыйча ташыганга муниципаль берәмлекләрне төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозган өчен

КоАП РТ 3.6 статьясындагы 1 өлеше нигезендә административ җаваплылык каралган (җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләрне бозу).

Шул ук вакытта әлеге статьяда гражданнарга кисәтү ясау яисә 2000 алып 3500 кадәр, юридик затларга 200 000 алып 500 000 кадәр административ штраф каралган.

Йөкне капламыйча ташучыларның күбесен юридик затлар тәшкил итә.

Күрсәтелгән хокук бозуларның җәмгыять өчен куркынычлылык дәрәҗәсен исәпкә алып, гадел һәм дөрес административ җаваплылык билгеләү максатларында закон проекты белән аны аерым состав итеп карау тәкъдим ителә.

Әйтелгәннәрдән чыгып, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенә таләпләрне бозу турында яңа – 3.19 статья өстәлә. Аның нигезендә йөк транспорты чарасын арбадагы (контейнердагы) чәчелүчән йөкләрне, чүп-чарны, җиңел тараны, киселгән агачларны, яфракларны брезент яисә башка материал белән капламыйча файдалануда чагылган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенең җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләрен бозган өчен гражданнарга – биш мең сум күләмендә; юридик затларга илле мең сум күләмендә административ штраф салу тәкъдим ителә.

Шулай ук фотога һәм киногa төшерү, видео яздыру буенча махсус функцияләре булган автомат режимда эшләүче техник чаралар яисә фото, кино төшерү һәм видео яздыру җайланмалары теркәгән административ хокук бозулар өчен беркетмә төземи генә административ җаваплылыкка тартуның гадиләштерелгән тәртибе дә карала.

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законына да шундый ук үзгәрешләр кертелә.

Закон проектын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

## ИСЕМЛЕГЕ

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәрешләр кертү яки кабул итү таләп ителми.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанс белән тәэмин итүне таләп итми.